**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 17 декабрендәге 5185 номерлы карары**

**Казан шәһәре торак фондында торак урыннан**
**файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау турында»гы әмере нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәренең дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләүне (1 номерлы кушымта) расларга. Наем өчен түләү әлеге карарга 1 номерлы кушымтадагы хисап нигезендә исәпләнгән дифференциацияләнгән ставкалар буенча айга торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрына билгеләнә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитетына (В.А.Лысачкин) социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылар өчен торак урыннан файдалануга түләүне (наем өчен түләүне) һәм наем өчен вакытында түләмәгән һәм (яки) тулысынча түләмәгән өчен яллаучыларга исәпләнгән пеняларны Казан шәһәре бюджетына кертүне тәэмин итәргә.

3. Оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга (идарәче оешмалар, торак милекчеләре ширкәтләре, торак һәм башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары) ай саен, наем өчен түләүне билгеләү, җыю, түләттерү һәм күчерүдә хезмәттәшлек итү турында шартнамәдә билгеләнгән акчаларны

күчерү вакыты чыккан көннән алып биш эш көне эчендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитетына әлеге карарның 2 номерлы кушымтасындагы формалар нигезендә наем өчен түләү буенча билгеләнгән, җыелган (түләттерелгән) һәм Казан шәһәре бюджетына күчерелгән түләү һәм пенялар турында мәгълүмат тапшырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 15 декабрендәге 4112 номерлы «Казан шәһәренең торак фондында торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
5185 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2016 елның 22 декабрендәге 5253 номерлы карары белән расланган**
**Казан шәһәренең дәүләт яки муниципаль торак фондының**
**торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм наем**
**шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылар өчен**
**торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен**
**исәпләү тәртибе турындагы нигезләмә буенча**
**наем өчен түләү күләмен исәпләү**

Наем өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Пн = Нбаз \times \frac{К1 + К2 + К3}{3} \times Ксп \times S,$$ биредә:

Пн – торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме;

Нбаз – Казан шәһәрендә торак урынның 1 кв.метрын наемга алу өчен түләүнең база күләме – 137,56 сум;

Ксп – түләү тәңгәллеге коэфициенты:

- социаль наем шартнамәләре буенча – 0,10;

- Казан шәһәренең дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча – 0,10;

S – дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урынын социаль наемга алу шартнамәсе яисә наемга алу шартнамәсе буенча бирелгән торак урынның гомуми мәйданы (кв.м).

К1 түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К1 = \frac{Км + Ксв + Кпл}{3},$$ биредә:

К1, К2, К3, Км, Ксв, Кпл – таблицада күрсәтелгән коэффициентлар.

| **Коэффициент** | **Куллану үзенчәлекләре** | **Коэффициент күрсәткече** |
| --- | --- | --- |
| Торак урынның сыйфатын характерлаучы коэффициентлар (К1) | | |
| Км | Стеналар материалы:<br>- кирпеч, таш;<br>- блоклы, эре панельле;<br>- катнаш яки агач | <br>1,3;<br>1,1;<br>0,8 |
| Ксв | Йортларны кулланышка кертү вакытлары:<br>- 2011 елдан;<br>- 1991 елдан 2010 елга кадәр;<br>- 1971 елдан 1990 елга кадәр;<br>- 1951 елдан 1970 елга кадәр;<br>- 1950 елга кадәр | <br>1,3;<br>1,2;<br>1,0;<br>0,9;<br>0,8 |
| Кпл | Торак урын планы:<br>- яхшыртылган;<br>- стандарт;<br>- стандарт булмаган (шул исәптән коммуналь, кунакханә һәм барак тибындагы, тулай торак) | <br>1,3;<br>1,1;<br>0,8 |
| Торак урынны төзекләндерүне характерлаучы коэффициент (К2) | | |
| - | Торак урынны төзекләндерү:<br>- төзекләндерүнең барлык төрләре: салкын, кайнар су белән тәэмин итү, үзәкләштерелгән су чыгару, җылыту (мичтән тыш), электр белән тәэмин итү хезмәтләре булу;<br>- бер төр уңайлылыкның булмавы;<br>- бер төрдән артык уңайлылыкның булмавы | <br>1,3;<br><br><br><br>1,0;<br>0,8 |
| Йортның урнашу урынын характерлаучы коэффициент (К3) | | |
| - | Урнашу урыны<br>- Авиатөзелеш районы;<br>- Вахитов районы;<br>- Киров районы;<br>- Мәскәү районы;<br>- Яңа Савин районы<br>- Идел буе районы;<br>- Совет районы | <br>0,8;<br>1,3;<br>0,8;<br>1,1;<br>1,3;<br>1,1;<br>1,1 |

___

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
5185 номерлы карарына
2 номерлы кушымта
(1 форма)

**________ елның _____ аена наем өчен билгеләнгән,**
**җыелган (түләттерелгән) һәм Казан шәһәре бюджетына күчерелгән түләү турында**
**МӘГЪЛҮМАТ**

| **Адресы (урам, йорт)** | **Хисап ае башына муниципаль торак фонды мәйданы, кв.м** | **Наем өчен билгеләнгән түләү** | | **Наем өчен җыелган (түләттерелгән) түләү** | | **Казан шәһәре бюджетына наем өчен күчерелгән түләү** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **ел башыннан, сум** | **шул исәптән хисап аена, сум** | **ел башыннан, сум** | **шул исәптән хисап аена, сум** | **ел башыннан, сум** | **шул исәптән хисап аена, сум** |
| | | | | | | | |
| **БАРЛЫГЫ** | | | | | | | |

Җитәкче ____________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Баш бухгалтер ____________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Башкаручы ____________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тел. ________________________

(2 форма)

**________ елның _____ аена Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә наем өчен түләү буенча билгеләнгән, җыелган (түләттерелгән) һәм Казан шәһәре бюджетына күчерелгән пенялар турында**

**МӘГЪЛҮМАТ**

| **Адресы (урам, йорт)** | **Хисап ае башына муниципаль торак фонды мәйданы, кв.м** | **Наем өчен түләү буенча билгеләнгән пенялар** | | **Наем өчен түләү буенча җыелган (түләтелгән) пенялар** | | **Наем өчен түләү буенча Казан шәһәре бюджетына күчерелгән пенялар** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **ел башыннан, сум** | **шул исәптән хисап аена, сум** | **ел башыннан, сум** | **шул исәптән хисап аена, сум** | **ел башыннан, сум** | **шул исәптән хисап аена, сум** |
| | | | | | | | |
| **БАРЛЫГЫ** | | | | | | | |

Җитәкче ____________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Баш бухгалтер ____________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Башкаручы ____________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тел. ________________________

_______________